# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«06»апрель  2024 ел № 3**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Түбән Аты авылында  халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Түбән Аты  авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясынигезендә,Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлегенең Урта Аты авылында 2024 елның 06 апрелендә "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлегенең Түбән Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча узган халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә  бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда  яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы  Урта Аты  авыл җирлеге Түбән  Аты  авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган  кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге  формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын)  түләүдән азат итү  һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл  итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау ( урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру)
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл япмасын ремонтлау)

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпаны комплектлау белән сатып алу (янгын сүндерү култыгы, суырткыч култыгы, янгын сүндерү очлыгы)
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасының насос станциясе бинасы төзелеше)
-коелар ясау, ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Кече урамындагы чишмәгә материаллар сатып алу һәм ремонт эшләрен башкару)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 326 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 178 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 178 кеше тавыш бирде;
" Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегендә Түбән Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү мәсьәләсе буенча карарны танырга: «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Тубән Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау ( урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл япмасын ремонтлау)

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпаны комплектлау белән сатып алу (янгын сүндерү култыгы, суырткыч култыгы, янгын сүндерү очлыгы)

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасының насос станциясе бинасы төзелеше)

-коелар ясау, ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Кече урамындагы чишмәгә материаллар сатып алу һәм ремонт эшләрен башкару)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда кабул ителгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урамы, 37 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Батталова Р.Х